## «КАЗАН КРЕМЛЕ» МУЗЕЙ-ТЫЮЛЫГЫ

2023 елның 20 маенда «Казан Кремле» музей-тыюлыгы ел саен үткәрелә торган «Музейлар төне» бөтенроссия акциясенә кушыла. Бу көнне 18:30 сәгатьтән 23:00 сәгатькә кадәр музей-тыюлыкның музейларында һәм күргәзмә залларында тематик экскурсияләр, театральләштерелгән программалар, мастер-класслар, квестлар һәм башка чаралар узачак.

Чараларда катнашу өчен алдан язылу кирәк.

**Ел саен үткәрелә торган «Музейлар төне» бөтенроссия акциясе программасы**

**Керү билеты буенча түбәндәге чараларда, иҗади дәресләрдә һәм мастер-классларда катнашырга мөмкин**

### «ЭРМИТАЖ-КАЗАН» ҮЗӘГЕ

***БӘЯСЕ:*** *өлкәннәр –* ***350 сум.****, студентлар, пенсия яшендәгеләр –* ***250 сум.****, 18 яшькә кадәрге балалар –* ***150 сум***

| | |
|---|---|
| **18:30 - 22:30** | **Дәүләт Эрмитажы тупланмасы күргәзмәсендә бүләкләр уйнату, 6+**<br>Күргәзмәнең бүләген уйнату: шопер-сумка, блокнот, карандаш, стикерпак, саны чикләнгән хуш ис һәм «Александр Македонский. Көнчыгышка юл» күргәзмәсе каталогы |
| **18:30-21:00** | **«Төнлә укы!» «Александр Македонский. Көнчыгышка юл» күргәзмәсендә Эрмитаж китапханәсе, 6+**<br>Катнашучылар Македонскийның көнчыгышка походы һәм күргәзмәдә тәкъдим ителгән сәнгать әсәрләре турында китаплар белән танышачак. Соңгы елларда музей китапханәсенә кергән сирәк һәм уникаль китапларны күрү һәм уку мөмкинлеге булачак. |
| **18:30-21:00** | **«Борнгы Грециядә портрет», 6+**<br>«Александр Македонский портретлары. Тарих һәм миф» фильмын күрсәтү |
| **18:30, 19:30, 20:30, 21:30** | **«Александр Македонский. Көнчыгышка юл» күргәзмәсендә Казан дәүләт мәдәният институты студентлары катнашында "Җанлы геройлар" театральләштерелгән программа, 6+**<br>Олимпиада, Дарий, Бодхисаттва, Птолемей һәм Македонский тарихта иң бөек империянең барлыкка килү тарихын бәян итәчәк. Олимпиада улының Азия патшасы булуы, Дарий һәм Птолемей македониялеләр һәм фарсылар сугышы, Бодхисаттва Македоскийның Һиндстанга тартылуының серле көче турында сөйлиячәк. |
| **19:00, 20:00, 21:00, 22:00** | **Казан дәүләт мәдәният институты студентлары катнашында шорт-экскурсия, 6+**<br>Һәр залда хикәячеләр бөек геройның тормыш һәм вакыйгаларның хронологиясен ачачак, күргәзмәдә төрле әсәрләр һәм мәдәниятләр белән таныштырачак |

## ТАТАРСТАННЫҢ ТАБИГЫЙ ТАРИХ МУЗЕЕ

***БӘЯСЕ:** өлкәннәр – **350 сум.**, студентлар, пенсия яшендәгеләр – **250 сум.**, 18 яшькә кадәрге балалар – **150 сум***

| | |
|---|---|
| **19.30** | **«Сезнең баш сөягегез искиткеч: имезүчеләрнең баш сөягенең эволюциясе, төзелеше һәм төрлелеге», 12+**<br>Баш сөяге-тере организмның төзелеше буенча иң катлаулы һәм әһәмияте буенча иң мөһим өлешләренең берсе. Лекциядә сез төрле имезүчеләрнең баш сөягенең төзелеше, аның ничек үзгәрүе һәм нәрсә белән бәйле булуы турында белерсез.<br>КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институтының зоология һәм гомуми биология кафедрасы аспиранты Ветлужский Сергей Дмитриевичтан лекция |
| **19.00, 19.30**<br>**20.00, 20.30** | **«Дөнья асылташлары» экскурсиясе, 6+**<br>«Җир минераллары» залы буенча минералларның табигый үрнәкләрен тәкъдим итү.<br>Нефть-газ технологияләре геологиясе институты доценты Глухов Михаил Сергеевичтан экскурсия |
| **19.00, 19.30**<br>**20.00, 20.30** | **«Казан диңгезе» медиа-инсталяция, 0+**<br>«Казан диңгезе» залының икенче катында тамашачылар моннан 270 млн ел элек Казан диңгезендә яшәгән, хәзер калдыклары җир астында табылучы хайван төрләре турында 10 минутлык фильм карый алачак |
| **21.00, 21.30**<br>**22.00, 22.30** | **«Төнге экскурсия», 6+**<br>Төн җитү белән музейның дүрт залы - «Җанварсыман кәлтәләр дәвере» залы, «Диңгез сөйрәлүчеләре», «Динозаврлар дәвере», «Имезүчеләр дөньясы» - караңгылыкка чума. Бу төнне музейда утлар сүнә һәм тамашачылар башка чынбарлыкка эләгәчәк. Экскурсиядә музей залында төнге сәгатьләрдә, ишекләр ябылгач ниләр булганын beləсегез килсе, рәхим итегез. Үзегез белән телефон (яки фонарь) алсагыз яхшы булачак. |
| **18.30-22.30** | **Зирәк уеннар, 6+**<br>"Җир асты байлыклары" залында өстәл уеннарын яратучылар мәйданчыгы эшләячәк. Музейга килүче һәр кеше Минерал эзләүчеләр, Мемо, Дженга, Эволюция, Уно, Крокодил, Цуро, Барабашка һәм Сүз остасы кебек уеннар уйный алачак |
| **18.30-22.30** | **«Төнге җәнлекләр» кәгазь эшләнмәләр буенча мастер-класс, 6+**<br>Мастер-класста сез кәгазьдән күбесенчә төнге тормыш алып баручы төрле җәнлекләр ясый һәм аларны үзегез белән өйгә алып кайтып китә аласыз. Сездән бераз гына тырышлык кирәк булачак. Эш барышында хезмәткәр бу гаҗәеп җан ияләре турында кызыклы мисаллар сөйләр |

## «МАНЕЖ» КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЫ

***БӘЯСЕ:*** *өлкәннәр –* ***200 сум.****, студентлар, пенсия яшендәгеләр –* ***150 сум.****, 18 яшькә кадәрге балалар –* ***100 сум***

**18.30** **«Карикатураларда совет чоры» гаилә программасы, 6+**

Уен формасында программада катнашучылар карикатура сәнгате һәм совет көнкүреше мәдәнияте белән танышачак, үткәнгә кайтып 1960-1980 еллардагы коммуналь фатирда булачак, анда коммуналь йортларның нәрсә икәнен, аларның барлыкка килү тарихын һәм яшәү үзенчәлекләрен беләчәк. Катнашучыларны табышмаклар, ребуслар һәм викторина көтә.

**19.30** **«Чигелгән картиналар» галереясе осталарыннан чигү буенча мастер-класс, (Мәскәү шәһәре), 12+**

"Дөнья матур" күргәзмәсендә катнашучы тамашачылар белән очрашып, күргәзмә һәм Россиянең барлык почмакларыннан чигүчеләрне берләштергән шул ук исемдәге проект белән танышырга мөмкин булачак

**20.30** **«Коммуналка» арт-киңлеге буенча куратор экскурсиясе, 6+**

Концепция авторы һәм коммуналь фатир буенча «старэий», тарихчы, коллекционер Григорий Ивойлов автор экскурсиясе үткәрәчәк. Сез тарихи киңлекләрне колачлый алачаксыз. Кем өчендер бу балачакка кайту, кем өчендер таныш булмаган чор, әмма һәркемгә кызыклы сәяхәт ясарга һәм совет тормышы тарихына чумарга кызык булачак

## ТАТАР ХАЛКЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТЧЕЛЕГЕ ТАРИХЫ МУЗЕЕ

***БӘЯСЕ:*** *өлкәннәр – 15****0 сум.****, студентлар, пенсия яшендәгеләр –* ***100 сум.****, 18 яшькә кадәрге балалар –* ***80 сум***

**19:00** **«XIX гасыр бию мәдәнияте» «Fleur de la danse» бию студиясеннән лекция,6+**

Казан XIX гасырда Россиянең эре губернасы үзәге, дәүләт һәм дөньяви тормышның бергә тупланган, Казан Кремле җирлегендә Россия императорының шәхси резиденциясе булган шәһәр.

1798 елда император Павел I башкалабызга килүе хөрмәтенә Казан Кремлендәге Гавами урыннары бинасында беренче бал оештырыла. Анда югары даирә әгъзаларыннан тыш, татар сәүдәгәрләренең иң бай вәкилләре, руханилар, шул исәптән мөфти дә чакырыла.

## <u>ИСЛАМ МӘДӘНИЯТЕ МУЗЕЕ</u>

***БӘЯСЕ:*** *өлкәннәр – 20****0 сум.****, студентлар, пенсия яшендәгеләр, 18 яшькә кадәрге балалар – 10****0 сум***

**18.30**

**Казанның беренче Коръән басмасының 220-еллыгына багышланган күргәзмә буенча экскурсия, 6+**

Экскурсиядә катнашучылар КФУ фәнни китапханәсеннән, ТР Милли китапханәсеннән, ТР мөселманнары Диния нәзарәтеннән, ТР ФА Язма мирас үзәгеннән, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы фондларыннан уникаль әйберләр белән танышачак. Күргәзмәнең сирәк артефактлары арасында Коръәннең төрле форматтагы беренче басмалары, фотоматериаллар бар. Экспозициягә Казан басмасының шрифты һәм график үзенчәлекләре белән таныштыручы мультимедия һәм видеоматериаллар кертү күздә тотыла

**19.00**

**«Казанның җәмигъ мәчетләре» күргәзмәсе буенча экскурсия, 6+**

Экскурсиядә Казанның революциягә кадәрге, заманча һәм проектланучы җомга мәчетләренең архитектура үзенчәлекләре, төзелеше һәм эшчәнлеге тарихы белән танышырга мөмкин булачак. Күргәзмәдә тәкъдим ителгән мәчетләр үткән, хәзерге һәм киләчәк архитектурасында төрле традицияләр һәм стильләр диалогын күрсәтә

**19.30, 20.30 21.30**

**«Кол Шәриф серләре» квест, 6+**

Риваять буенча мәчет имамы Кол Шәриф квестта катнашучылар өчен бик күп биремнәр әзерләгән!

## <u>БЛАГОВЕЩЕНИЕ СОБОРЫ ТАРИХЫ МУЗЕЕ</u>

***БӘЯСЕ:*** *өлкәннәр –* ***150 сум.****, студентлар, пенсия яшендәгеләр –* ***100 сум****, 18 яшькә кадәрге балалар –* ***80 сум***

**18.30**

**«Пасханы каршылап» күргәзмәсе һәм Благовещение соборы тарихы музее буенча экскурсия, 6+**

Музей экспозициясе буенча экскурсия тамашачыларны гасырлар дәвамында Благовещение соборы тарихы, аның тышкы һәм эчке күренешләрендә булган үзгәрешләр, шулай ук эш-гамәлләре собор һәм Казан православиесе язмышына йогынты ясаган танылган шәхесләр белән таныштыра.

**19.00**

**Музей һәм вакытлы күргәзмә буенча квест, 6+**

Казан мәчесе - кызыклы хайван. Кайда тели шунда йөри. Менә ул Благовещение соборына кереп аны гөмбәзеннән алып җир асты гыйбадәтханәсенә кадәр йөреп чыккан. Ә хәзер музейның яшь кунакларына собор турында табышмаклар бирергә карар иткән.

**19.45**

**«Тәүратның рус мәдәниятенә йогынтысы» фәнни-популяр лекция, 12+**

Лектор Ю.Г. Матушанская, филология фәннәре докторы, КФУ профессоры

Изге язмалар дөнья мәдәниятенә, шул исәптән рус мәдәниятенә дә көчле йогынты ясый.  Бу йогынтының эзләрен төрле мәдәни өлкәләрдә хокукый өлкәләрдән алып сәнгатьнең төрле төрләренә кадәр табарга мөмкин. Лекция Изге язманың рус мәдәниятенә йогынтысына багышланачак

## ТУП УТАРЫ МУЗЕЕ

***БӘЯСЕ:** өлкәннәр – 20**0 сум.**, студентлар, пенсия яшендәгеләр, 18 яшькә кадәрге балалар – 10**0 сум***

| | |
|---|---|
| **21.00** | **«Кубачи-Зирехгеран. Осталар шәһәре» күргәзмәсе буенча «Кубачига сәяхәт» квест-экскурсия, 6+**<br>Программада катнашучылар дөньякүләм танылган алтын коючы – кубачилыларның борынгы шәһәренә сәяхәткә чыгачак. Квест - экскурсия барышында кунаклар кубачилыларның яшәү рәвеше, халык һөнәрләре һәм осталарның серләре белән танышып кына калмыйча, мөһим артефакт – хәнҗәрне таба алачак |
| **с 18.30 до 23.00** | **«Кубачи-Зирехгеран. Осталар шәһәре» күргәзмәсе буенча квест-сәяхәтнамә, 6+**<br>Квест- сәяхәтнамә Кубачи һәм кубачилылар дөньясына үзенчәлекле юл күрсәтүче була. Күргәзмәнең иң кызыклы экспонатлары белән бәйле юл күрсәткечләре биремнәрен үтәп, кунаклар традицион кулланма сәнгать белән танышачак һәм Кубачи авылының үзенчәлекле мәдәнияте белән танышачак |

## ГАВАМИ УРЫННАРЫ КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫ

***БӘЯСЕ:** өлкәннәр – 45**0 сум.**, студентлар, пенсия яшендәгеләр – **350 сум,** 18 яшькә кадәрге балалар – 30**0 сум***

| | |
|---|---|
| **18.30, 20.00** | **«Алпар» татар этно-төркеме башкаруында концерт һәм «Татар костюмы: традицияләр һәм трансформация» күргәзмәсе буенча экскурсия, 0+**<br>Сезне милли татар костюмына багышланган күргәзмә буенча экскурсия көтә, анда сез калпак белән калфак арасындагы аерманы, ни өчен татар читекләренең 20 гасыр башында Европада Россия символына әверелүен һәм башка күп нәрсәне белерсез.<br>Алга таба сезнең алдыгызда яшь татар этно-төркеме «Алпар» чыгыш ясаячак. Музыкантлар ятаган, думбра, кыл-кубыз, курай, бас домбра, саз кебек уен коралларында уйный. Бу һәм башка уен кораллары да күргәзмәдә тәкъдим ителә.<br>Коллектив репертуарында дастан, касыйда, бәет һәм мөнәҗәт жанрындагы аутентик этнографик көйләр дә, урта гасыр татар шагыйрьләре Кол Гали, Сәиф Сараи һәм Мөхәммәтяр сүзләренә автор стильлендәге музыкадан торган җырлар да бар. |

## ИНКЛЮЗИВ ПРОГРАММАЛАР

***БӘЯСЕ:** түләүсез*

| | |
|---|---|
| **20.00** | **Казан Кремле территориясе буенча рус ишарәләр телендә экскурсия (ишетмәүчеләр һәм начар ишетүчеләр өчен), 6+**<br>Чара түләүсез.<br>+7 (986) 917-78-61 (WhatsApp) телефоны буенча язылырга мөмкин |

## ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮ БУЕНЧА

| | | |
|---|---|---|
| | **«ЭРМИТАЖ-КАЗАН» ҮЗӘГЕ** | |
| **18:30, 19:30, 20:30, 21:30** | **Грек рәсеме буенча мастер-класс, 6+**<br>Мастер-класста катнашучыларга грек рәсеме сәнгате, кара һәм кызыл фигуралы стиль турында сөйләячәкләр. Грек савытларының төп төрләрен карап чыгып, автор рәсемнәрен ясарга мөмкин булачак | *Бәясе:*<br>*Өлкәннәр – 400 сум,*<br>*Пенсионерлар, студентлар – 300 сум,18 яшькә кадәр балалар – 200 сум* |
| | **ТАТАРСТАННЫҢ ТАБИГЫЙ ТАРИХ МУЗЕЕ** | |
| **19.00** | **«Фәнни хәзинәләр» фәнни интерактив шоу, 6+**<br>Борынгы милли риваятьләрне, әкиятләрне искә төшерик һәм аларның фәнни яктан ничек аңлатылуын белербез! Борынгы хатлар безгә ут сулый торган аждаһалар, исәпсез-хисапсыз байлыклар турында сөйли. Фән безгә риваятьләрнең һәм әкиятләрнең дөреслеген тикшерергә ярдәм итәчәк | *Бәясе 450 сум* |
| | **ИСЛАМ МӘДӘНИЯТЕ МУЗЕЕ** | |
| **18.30-20.30** | **каллиграфия остасы Әлфия Исхаковадан «Тугра» мастер-класс, 6+**<br>Бу дәрестә матур һәм нәфис язу остасы туграның каллиграфик жанры турында сөйләячәк, гарәп хәрефләре белән сезнең исемнәрегезне язачак. Безнең музейның һәр кунагы бу истәлекле сувенирны үзе белән алып китәчәк | *Бәясе 150 сум* |
| | **ТУП УТАРЫ МУЗЕЕ** | |
| **18.30** | **Һөнәри мастер-класс, 6+**<br>Мастер-класс кысаларында катнашучылар чүкеп ясау техникасы белән танышачак (чүкеп ясау урта гасыр технологияләре буенча йомшак металл кулланып башкарыла), шулай ук күн эшкәртү алымнары үзенчәлекләрен беләчәк (катнашучылар үзләре күн бөтигә төшерү өчен рәсем сайлый алалар). | *Бәясе 150 сум* |
| **19.45** | **«Кою эше» мастер-классы, 6+**<br>Аккургаштан бөтиләр һәм фигуралар коеп чыгару. Сувенир ясау формасын кунаклар үзләре сайлый ала. Дәрес барышында оста катнашучыларга технология үсеше турында сөйли | *Бәясе 150 сум* |

«МАНЕЖ» КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЫ

**18.30** **«Чигүле кыстыргыч» мастер-класс, 12+** *Бәясе 150 сум*

Катыргы һәм мулине белән китаплар өчен кыстыргыч ясау. Укыганда, без сәяхәт итәбез, хыялланабыз, өйрәнәбез, илһамланабыз һәм вакыт үткәнен онытып җибәрәбез. Китаптан аерылганда, иң мөһиме, тукталган урынны югалтмаска кирәк. Моңа файдалы аксессуар ярдәм итә. Ул теләсә нинди булырга мөмкин, ләкин үз куллары белән ясалганны куллану күпкә рәхәтрәк. Мастер-класс үзенең популярлыгын югалтмаган борынгы кул эшләре төрләренең берсе булган крестлы чигү турында хикәя белән озаталып бара

**БЛАГОВЕЩЕНИЕ СОБОРЫ ТАРИХЫ МУЗЕЕ**

**21.00-23.00** **«Борынгы рус каллиграфиясе» мастер-класс, 6+** *Бәясе 150 сум*

Каллиграфия буенча дәресләрне рәссам график, каллиграф, Россия Рәссамнары иҗат берлеге әгъзасы Владислав Баранов үткәрә

## Күргәзмәләр

| | |
|---|---|
| «Александр Македонский. Көнчыгышка юл» | «Эрмитаж-Казан» үзәге |
| «Кубачи-Зирехгеран. Осталар шәһәре» | Туп утары музее |
| «Дөнья матур!» | «Манеж» күргәзмә залы |
| «Чиста көмеш, затлы мехлар» | Гавами бинасы, 1 подъезд, 2 кат |
| «Татар костюмы – традицияләр һәм трансформация» | Гавами бинасы, 1 подъезд, 2 кат |
| «Казан гасырлар манзарасында» | Гавами бинасы, 2 подъезд, 2 кат |
| «Калашников. Солдат. Конструктор. Легенда» | Гавами бинасы, 2 подъезд, 2 кат |
| «Үзгәрешләр чоры мәдрәсәсе» | Ислам мәдәнияте музее |
| «Казанның җәмигъ мәчетләре» | Ислам мәдәнияте музее |
| «Пасханы каршылап» | Благовещение соборы тарихы музее |
| «Алтын киселеш», рәссам Әнвәр Сәйфетдинов күргәзмәсе | Татар халкы һәм Татарстан Республикасы дәүләтчелеге тарихы музее |

## Элемтә ысулы

**Экскурсия бүлеге**
+7 (843) 567-81-42
excurs.kremlin@tatar.ru

**«Эрмитаж-Казан» үзәге**
+7 (843) 567-80-34
+7 (843) 567-80-32
hermitage-kazan@mail.ru

**Татар халкы һәм Татарстан Республикасы дәүләтчелеге тарихы музее**
+7 (843) 567-80-24
muz_kazankreml@mail.ru

**Татарстанның табигый тарих музее**
+7 (843) 567-80-35
+7 (843) 567-80-37
tabigat06@mail.ru

**Ислам мәдәнияте музее**
+7 (843) 567-81-25
+7 (843) 567-81-52
islammuseum@yandex.ru

**«Манеж» күргәзмә залы**
+7 (843) 567-80-67
kremlin-manege@yandex.ru

**Туп утары музее**
+7 (843) 567-81-61
+7 (843) 567-81-60
push.dvor@bk.ru

**Гавами бинасы күргәзмә заллары**
+7 996 606-21-44
prisutstvennyemesta@yandex.ru